КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 13 ноябрь г.Казань № 1071

«Сабандагы 9 нчы балалар стоматология поликлиникасы» акционерлык җәмгыятен оештыру турында

Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтеннән нәтиҗәле файдалану максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Сабандагы 9 нчы балалар стоматология поликлиникасы» акционерлык җәмгыятен гамәлгә кую юлы белән, җәмгыятьнең устав капиталында Татарстан Республикасы өлешен кимендә 25 процент плюс бер акция итеп тәэмин итү шарты белән оештыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына:

оештырыла торган акционерлык җәмгыятенең устав капиталына Татарстан Республикасы исеменнән кушымта нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен һәм медицина җиһазын кертергә;

бәяләү эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә оештырыла торган «Сабандагы 9 нчы балалар стоматология поликлиникасы» акционерлык җәмгыятенең устав капиталына Татарстан Республикасы исеменнән кертелә торган Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен бәяләүне тәэмин итәргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 13 ноябрь, 1071 нче
карарына кушымта

Татарстан Республикасы исеменнән
«Сабандагы 9 нчы балалар стоматология поликлиникасы»
акционерлык җәмгыятенең устав капиталына кертелә торган
Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте
исемлеге

| Т/с | Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте исеме | Урнашу урыны адресы | Мәйданы, кв.метр |
|---|---|---|---|
| 1. | Бина урыны, билгеләнеше: торак булмаган, кадастр саны: 16:50:100401:3867 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Сабан урамы, 1 нче йорт, 31, 32, 35, 36, 37, 38, 39, 40, 42, 43, 44, 46, 47 нче урыннар | 129,1 |
| 2. | Бина урыны, билгеләнеше: торак булмаган, кадастр саны: 16:50:100401:3536 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Сабан урамы, 1 нче йорт | 445,6 |
| 3. | Бина урыны, билгеләнеше: торак булмаган, кадастр саны: 16:50:100401:3775 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Сабан урамы, 1 нче йорт, 33, 34, 41, 45 нче урыннар | 59,0 |